КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 21 май г.Казань № 384

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Г.Р.Державин исемендәге республика премиясе турында» 2016 ел, 14 апрель, 223 нче карары белән расланган Г.Р.Державин исемендәге республика премиясе комитеты составына үзгәрешләр кертү хакында

Аерым затларның башка эшкә күчүенә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Г.Р.Державин исемендәге республика премиясе турында» 2016 ел, 14 апрель, 223 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 25 май, 298 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Г.Р.Державин исемендәге республика премиясе комитеты составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Комитет составыннан В.Г.Шәйхразиевны, Р.Х.Корбановны, А.М.Сибагатуллинны, Э.Н.Фәттаховны чыгарырга;

Комитет составына түбәндәгеләрне кертергә:

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Комитет рәисе Ләйлә Ринат кызы Фазлыеваны;

Татарстан Республикасының мәдәният министры Ирада Хафизҗан кызы Әюпованы;

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасының мәгариф һәм фән министры Рафис Тимерхан улы Борһановны;

Татарстан Республикасының юстиция министры Рөстәм Илдус улы Заһидуллинны;

Татарстан Республикасы Язучылар берлеге рәисе Данил Хәбибрәхман улы Салиховны (килешү буенча);

Л.Ю.Глухова вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт-хокук идарәсе башлыгы (килешү буенча)».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин